# КАРАР

24 ноябрь, 2023 ел № 2

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Вахит авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 6550 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Вахит авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

2) Вахит авылында һәйкәлне төзү, ремонтлау һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

3) Вахит авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

4) Вахитово авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау; Вахит авылында урам яктыртуны карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

5) Вахит авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

6) парклар, яр буйлары, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

7) җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту, тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

8) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

9) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм оештыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

10) массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазландыру;

11) Чишмәләрне, чишмә йортларын (будкаларын) һәм аларга якын территорияләрне урнаштыру, төзү, ремонтлау һәм тоту, чишмәгә керү юлларына вак таш салу , асфальт җәю, парковкалар, яктырту урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 628 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 321 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 311 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 6550 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Вахит авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

2) Вахит авылында һәйкәлне төзү, ремонтлау һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

3) Вахит авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

4) Вахитово авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау; Вахит авылында урам яктыртуны карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

5) Вахит авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

6) парклар, яр буйлары, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

7) җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту, тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

8) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

9) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм оештыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

10) массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазландыру;

11) Чишмәләрне, чишмә йортларын (будкаларын) һәм аларга якын территорияләрне урнаштыру, төзү, ремонтлау һәм тоту, чишмәгә керү юлларына вак таш салу , асфальт җәю, парковкалар, яктырту урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов